# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 ел, 12 ноябрь №1

“Росиия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына белән 2024 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 мунутта “Сез ризамы?:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан кала, 500 ( биш йөз) сум күләмендә үз-үзенә салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
   1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар кору (зират коймасы өчен материаллар сатып алу)
   2) торак пункты чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (авыл эчендәге юлларны кыш һәм җәйге хезмәт күрсәтү (кардан урамнарны чистарту, трактор йөртүчесе хезмәт хакы, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу)
   3) торак пункт территориясен яхшырту (агачларны кисү)

“РИЗА” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 80 (сиксән) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 56 (илле алты) кеше, бу 70% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленгән: гражданнар җыенында катнашучы 56 (илле алты) “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирә; җыенда катнашучы 0 (ноль) “КАРШЫ” позициясе өчен тавыш бирә. Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас торак пунктында узган гражданнар җыенын танырга, җыен нәтиҗәләрен гамәлдә дип санарга.
2. 2025 елда татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Ювас авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими рәвештә авыл территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан кала, 500 ( биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар кору (зират коймасы өчен материаллар сатып алу)

2) торак пункты чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (авыл эчендәге юлларны кыш һәм җәйге хезмәт күрсәтү (кардан урамнарны чистарту, трактор йөртүчесе хезмәт хакы, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу)

3) торак пункт территориясен яхшырту (агачларны кисү)

4. 2025 елда үзара салым түләүдән азат итәргә:

а) 1 төркем инвалидлар

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муницпаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыен рәисе Г.Н.Сафина